ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　с. Верхний Услон　　_______________

2017 елга «Югары Ослан урта гомуми белем
бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта
гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ
инклюзив белем бирүне тормышка ашыруга
норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 гыйнварындагы 88-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 79 һәм 99 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10 - ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив чыгымнар эшләү турында» 2016 елның 06 ноябрендәге 01/2276 номерлы һәм «Инлюзив белем кысаларында норматив чыгымнар эшләү турында» 2017 елның 17 гыйнварындагы 01/68 номерлы хатлары нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ 2017 елга инклюзив белем бирү кысаларында сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга

2.Югары Ослан муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1 пункты нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　　　　　　Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
Л.В. Абрамова
5 нөсхәдә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 ел___________
№________ Карарына
1 нче кушымта

2017 елда «Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ инклюзив белем бирү кысаларында мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү учреждениесе исеме | | Гомуми белем бирү учреждениесендә гомуми белем дәрәҗәсе. | Сыйныф төре | Мәгариф профиле | Елына бер укучыга норматив, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | «Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ | Башлангыч гомуми белем | Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сыйныфлар | ишетү сәләте бозылган балалар өчен: ишетмәүчеләр, начар ишетүчеләр, соң ишетүчеләр | 52187 |
| 2. | «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ | Башлангыч гомуми белем | Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сыйныфлар | ишетү сәләте бозылган балалар өчен: ишетмәүчеләр, начар ишетүчеләр, соң ишетүчеләр | 52187 |